# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык  авылы торак пунктында гражданнар
җыены нәтиҗәләре турында

**30 март 2024 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге  131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлеге башлыгынын 20.03.2024 ел 1 нче номерлы "«Мортыштамак авыл җирлеге Боламык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 1 номерлы,  «Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык  торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 28 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык  торак пунктында гражданнар җыены билгеләү турында" карары нигезендә 2024 елның 30 мартында 14.00 сәгатьтә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән протокол төзелде. Гражданнар җыенына түбәндәге сораулар тәкъдим ителде.

«Мортыштамак авыл җирлеге Боламык торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 1 номерлы,  «Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык торак пунктында 2024 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 28 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

« 1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); 2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)? "

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 10 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -  7 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 7 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен  0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл жирлегенең Боламык торак пунктында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге сораулар буенча :

«Мортыштамак авыл җирлеге Боламык  торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 октябрендәге 1 номерлы,  «Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык  торак пунктында 2024 елда

гражданнарның үзара салымын кертү турында» 2023 елның 28 октябрендәге 2 номерлы гражданнар жыены карарларына үзгәрешләр кертергә ризамы, чараларны түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«1. Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); 2. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу)"

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Мортыштамак авыл җирлегенең Боламык мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы
Халык җыенында рәислек итүче Һадиуллин И.Н.